КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 июль г.Казань № 615

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 972 нче; 2019 ел, 24 июнь, 510 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның беренче абзацында «күпфатирлы йортта» сүзләреннән соң «торак урынны торак булмаган урынга күчерүне гамәлгә ашыру тәртибенә, күпфатирлы йортта» сүзләрен өстәргә;

16 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Планлы тикшерү үткәргәндә Инспекциянең вазыйфаи затлары Инспекция тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә әзерләнә һәм раслана торган тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) кулланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) куллану барлык юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне планлы тикшерү үткәргәндә гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерү үткәргәндә кулланыла торган тикшерү кәгазьләрендә (контроль сораулар исемлекләрендә) юридик затка һәм индивидуаль эшмәкәргә карата куела торган, үтәлеше ягыннан гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, мәдәни мирас объектларына (тарихый һәм мәдәни ядкәрләргә) зыян салу куркынычы, дәүләт иминлегенә куркыныч, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янавын булдырмау күзлегеннән аеруча мөһим булган мәҗбүри таләпләргә кагылышлы сораулар була.»;

23 нче пунктның 2 нче пунктчасында «күпфатирлы йортта урыннарны үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп ясауны гамәлгә ашыру тәртибе» сүзләрен «күпфатирлы йортта торак урынны торак булмаган урынга күчерүне гамәлгә ашыру тәртибе таләпләрен, күпфатирлы йортта урыннарны үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп ясауны гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләрне бозу фактлары турында» сүзләренә алыштырырга;

$30^1$ нче пунктның икенче – бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«югары рисктагы категория өчен – ике елга бер тапкыр;

шактый зур рисктагы категория өчен – өч елга бер тапкыр;

уртача рисктагы категория өчен – алты елга бер тапкырдан ешрак түгел һәм сигез елга бер тапкырдан сирәгрәк түгел;

түбән рисктагы категория өчен планлы тикшерүләр үткәрелми.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин